# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең залог йөкләмәләрен рәсмиләштергәндә дәүләт пошлиналары түләү буенча ташламалар турында

1 статья. Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләрен, крестьян (фермер) хуҗалыкларын һәм ярдәмче хуҗалыклары булган предприятиеләрне, оешмаларны һәм учреждениеләрне дә кертеп, авыл хуҗалыгы җитештерүен үстерү өчен максатчыл кредитлар алганда, шулай ук залог шартнамәләрен нотариаль таныклаганда, залогны теркәгәндә һәм әлеге теркәү хакында документ биргәндә аларның кредиторларын да дәүләт пошлинасы түләүдән азат итәргә.

2 статья. Әлеге Законның 1 статьясына кагылышлы авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан раслана.

3 статья. Әлеге Закон басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1996 елның 31 гыйнваре
№ 409